**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О ветеринарном деле в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
22 февраля 2023 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 13 июля 1993 года № 1934-XII «О ветеринарном деле в Республике Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 19 июля 2005 года № 89-ЗРТ) (Ведомости Верховного Совета Татарстана, 1993, № 6 – 7; Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2005, № 7 – 8; 2006, № 11 (I часть); 2007, № 4; 2008, № 1; 2011, № 11 (I часть); 2016, № 7 – 8; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2019, № 49 (часть I); 2020, № 26 (часть I); 2021, № 93 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 1 слова «полноценных и безопасных» заменить словами «полноценной и безопасной», слова «продуктов животноводства» заменить словами «продукции животного происхождения»;

2) в статье 5:
а) в абзаце третьем части 1 слова «продуктов животноводства» заменить словами «продукции животного происхождения»;
б) в части 6 слова «Президентом Республики Татарстан» заменить словами «Главой (Раисом) Республики Татарстан»;

3) в пункте 7 статьи 6 слова «продуктов животноводства» заменить словами «продукции животного происхождения»;

4) в наименовании главы 3 слова «животноводческой продукции» заменить словами «продукции животного происхождения»;

5) статью 14 изложить в следующей редакции:

«Статья 14. **Архитектурно-строительное проектирование, строительство, реконструкция и капитальный ремонт объектов капитального строительства, возведение некапитальных строений, сооружений, связанных с выращиванием и содержанием животных, производством, хранением продукции животного происхождения**

1. При архитектурно-строительном проектировании, строительстве, реконструкции и капитальном ремонте объектов капитального строительства, возведении некапитальных строений, сооружений, связанных с выращиванием и содержанием животных, производством, хранением продукции животного происхождения, в том числе используемых при ведении крестьянского (фермерского) хозяйства и личного подсобного хозяйства, должно быть предусмотрено создание условий содержания животных и производства продукции животного происхождения, соответствующих обязательным требованиям, соблюдение которых входит в предмет федерального государственного ветеринарного контроля (надзора), в том числе в целях предупреждения возникновения и распространения заразных болезней животных и предупреждения загрязнения окружающей среды отходами, образующимися при содержании животных и производстве продукции животного происхождения.

2. Строительство объекта капитального строительства и (или) возведение некапитального строения, сооружения, связанных с выращиванием и содержанием животных (за исключением выращивания и содержания животных для личного пользования, не связанного с осуществлением предпринимательской деятельности), производством, хранением продукции животного происхождения, допускается только при наличии заключения органа, осуществляющего федеральный государственный ветеринарный контроль (надзор), о соответствии планируемого размещения таких объекта капитального строительства, некапитального строения, сооружения обязательным требованиям, соблюдение которых входит в предмет федерального государственного ветеринарного контроля (надзора).»;

6) в статье 16:

а) в наименовании слова «животноводческой продукции» заменить словами «продукции животного происхождения»;

б) в части 1 слова «Продукты животноводства» заменить словами «Продукция животного происхождения», слово «должны» заменить словом «должна»;

в) в части 2 слова «животноводческой продукции» заменить словами «продукции животного происхождения»;

7) в статье 17:

а) в части 1 слова «Президент Республики Татарстан» заменить словами «Глава (Раис) Республики Татарстан»;

б) в части 4 слова «Президент Республики Татарстан» заменить словами «Глава (Раис) Республики Татарстан»;

8) в статье 18:

а) в наименовании слова «животноводческой продукции» заменить словами «продукции животного происхождения»;

б) в части 1:

в абзаце первом слова «животноводческой продукции» заменить словами «продукции животного происхождения»;

в абзаце втором слова «объектов, связанных с содержанием животных, переработкой, хранением и реализацией продуктов животноводства» заменить словами «объектов, связанных с выращиванием и содержанием животных, производством, хранением продукции животного происхождения, ее переработкой и реализацией»;

в абзаце четвертом слова «продуктов животноводства» заменить словами «продукции животного происхождения»;

в абзаце шестом слова «продуктов животноводства» заменить словами «продукции животного происхождения»;

в) в части 2 слово «безопасных» заменить словом «безопасной», слова «продуктов животноводства» заменить словами «продукции животного происхождения», слова «этих продуктов» заменить словами «этой продукции»;

9) статью 19 изложить в следующей редакции:

«Статья 19. **Изъятие животных и (или) продукции животного происхождения при ликвидации очагов особо опасных болезней животных**

1. При ликвидации очагов особо опасных болезней животных по решениям Кабинета Министров Республики Татарстан, принимаемым по представлениям лиц, указанных в статье 17 Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии», может производиться в случаях, установленных законодательством Российской Федерации в области ветеринарии, изъятие животных и (или) продукции животного происхождения для целей их утилизации с выдачей собственнику соответствующего документа о таком изъятии.

2. В случае, указанном в части 1 настоящей статьи, собственник животных и (или) продукции животного происхождения имеет право на возмещение ущерба, понесенного им в результате изъятия животных и (или) продукции животного происхождения для целей утилизации, в размере, равном стоимости изъятых и уничтоженных животных и (или) продукции животного происхождения, определенной на день, предшествующий дню принятия решения об установлении ограничительных мероприятий (карантина) в соответствии со статьей 17 Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии», за исключением случая, предусмотренного частью 4 настоящей статьи.

3. Возмещение стоимости животных и (или) продукции животного происхождения, указанной в части 2 настоящей статьи, производится за счет средств бюджета Республики Татарстан.

4. В случае выявления нарушений законодательства Российской Федерации в области ветеринарии, допущенных собственником и (или) владельцем животных и (или) продукции животного происхождения на объектах, связанных с выращиванием и содержанием животных, производством, хранением продукции животного происхождения, ее переработкой и реализацией, и установленных в рамках федерального государственного ветеринарного контроля (надзора), при возникновении или распространении очагов особо опасных болезней животных на этих объектах Кабинетом Министров Республики Татарстан размер возмещения стоимости животных и (или) продукции животного происхождения собственнику может быть уменьшен или в возмещении стоимости животных и (или) продукции животного происхождения может быть отказано.

5. Перечень случаев, при которых размер возмещения ущерба может быть уменьшен, порядок уменьшения такого размера и перечень случаев, при которых в возмещении ущерба может быть отказано, устанавливаются в соответствии с законодательством Российской Федерации.

6. Оценка стоимости изымаемых животных и (или) продукции животного происхождения, решение об уменьшении размера возмещения стоимости животных и (или) продукции животного происхождения или решение об отказе в возмещении стоимости животных и (или) продукции животного происхождения могут быть оспорены собственником животных и (или) продукции животного происхождения в суде.

7. Перечень особо опасных болезней животных и порядок изъятия животных и (или) продукции животного происхождения при ликвидации очагов особо опасных болезней животных устанавливаются в соответствии с законодательством Российской Федерации.»;

10) в части 3 статьи 21 слово «продуктов» заменить словом «продукции».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
09 марта 2023 года
№ 10-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 22 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 19 июлендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 6 – 7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 1; 2011, № 11 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда «терлекчелек продуктларын» сүзләрен «терлек продукциясен» сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяда:
а) 1 өлешнең өченче абзацында «терлекчелек продуктларының» сүзләрен «терлек продукциясенең» сүзләренә алмаштырырга;
б) 6 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

3) 6 статьяның 7 пунктында «терлекчелек продуктларын» сүзләрен «терлек продукциясен» сүзләренә алмаштырырга;

4) 3 бүлек исемендә «терлекчелек продукциясенең» сүзләрен «терлек продукциясенең» сүзләренә алмаштырырга;

5) 14 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14 статья. **Терлекләрне үстерүгә һәм асрауга, терлек продукциясен җитештерүгә, саклауга бәйле капиталь төзелеш объектларын архитектура-төзелеш ягыннан проектлау, төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау, капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар торгызу**

1. Терлекләрне үстерүгә һәм асрауга, терлек продукциясен җитештерүгә, саклауга бәйле, шул исәптән крестьян (фермер) хуҗалыгын һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкны алып бару өчен файдаланыла торган, капиталь төзелеш объектларын архитектура-төзелеш ягыннан проектлаганда, төзегәндә, реконструкцияләгәндә һәм капиталь ремонтлаганда, капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар торгызганда, терлекләрне асрау һәм терлек продукциясен җитештерү өчен федераль дәүләт ветеринария контроле (күзәтчелеге) предметы кысаларында мәҗбүри үтәлергә тиешле таләпләргә туры килерлек, шул исәптән терлекләрнең йогышлы авырулары килеп чыгуны һәм таралуны кисәтү, терлек асраганда һәм терлек продукциясен җитештергәндә барлыкка килә торган калдыклар белән әйләнә-тирә мохитнең пычрануын кисәтү максатларында, шартлар тудыру каралырга тиеш.

2. Терлекләрне үстерүгә һәм асрауга (терлекләрне эшкуарлык эшчәнлегенә бәйле булмаган шәхси куллану өчен үстерүдән һәм асраудан тыш), терлек продукциясен җитештерүгә, саклауга бәйле капиталь төзелеш объектын төзү һәм (яисә) капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар торгызу федераль дәүләт ветеринария контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органның бу капиталь төзелеш объектын, капиталь булмаган төзелмәне, корылманы планлаштырыла торган урнаштыруның федераль дәүләт ветеринария контроле (күзәтчелеге) предметы кысаларында мәҗбүри үтәлергә тиешле таләпләргә туры килүе турында бәяләмәсе булганда гына рөхсәт ителә.»;

6) 16 статьяда:

а) исемдә «терлекчелек продукциясен» сүзләрен «терлек продукциясен» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлештә «терлекчелек продуктлары» сүзләрен «терлек продукциясе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 өлештә «Терлекчелек продукциясен» сүзләрен «Терлек продукциясен» сүзләренә алмаштырырга;

7) 17 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

8) 18 статьяда:

а) татарча текстта исем үзгәрешсез кала;

б) 1 өлештә:

татарча текстта беренче абзац үзгәрешсез кала;

икенче абзацта «терлекләрне асрауга, терлекчелек продуктларын җитештерүгә, эшкәртүгә, саклауга һәм сатуга бәйле объектларны» сүзләрен «терлекләрне үстерүгә һәм асрауга, терлек продукциясен җитештерүгә, саклауга, эшкәртүгә һәм сатуга бәйле объектларны» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «терлекчелек продуктларын» сүзләрен «терлек продукциясен» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «терлекчелек продуктларының» сүзләрен «терлек продукциясенең» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 өлештә «терлекчелек продуктлары» сүзләрен «терлек продукциясе» сүзләренә алмаштырырга, «шушы продуктларны» сүзләрен «шушы продукцияне» сүзләренә алмаштырырга;

9) 19 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19 статья. **Терлекләрнең аеруча куркыныч авырулары чыганакларын юк иткәндә терлекләрне һәм (яисә) терлек продукциясен тартып алу**

1. Терлекләрнең аеруча куркыныч авырулары чыганакларын юк иткәндә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының 17 статьясында күрсәтелгән затлар тәкъдиме буенча кабул ителә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән терлекләр һәм (яисә) терлек продукциясе ветеринария өлкәсендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда юкка чыгару максатларында тартып алынырга мөмкин, мондый тартып алу турында милекчегә тиешле документ бирелергә тиеш.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән очракта терлекләр һәм (яисә) терлек продукциясе милекчесе юкка чыгару максатларында терлекләрне һәм (яисә) терлек продукциясен тартып алу аркасында аңа килгән зыянны тартып алынган һәм юк ителгән терлекләрнең һәм (яисә) терлек продукциясенең «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының 17 статьясы нигезендә чикләү чаралары (карантин) билгеләү турында карар кабул ителгән көнгә кадәрге көнгә билгеләнгән бәясенә тигез күләмдә түләттерү хокукына ия, әлеге статьяның 4 өлешендә каралган очрактан тыш.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән терлекләрнең һәм (яисә) терлек продукциясенең бәясе Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән түләнә.

4. Терлекләрне үстерүгә һәм асрауга, терлек продукциясен җитештерүгә, саклауга, эшкәртүгә һәм сатуга бәйле объектларда терлекләрнең һәм (яисә) терлек продукциясенең милекчесе һәм (яисә) хуҗасы тарафыннан ветеринария өлкәсендәге Россия Федерациясе законнарын бозуга юл куелуы һәм аның федераль дәүләт ветеринария контроле (күзәтчелеге) кысаларында билгеләнүе ачыкланган очракта, бу объектларда терлекләрнең аеруча куркыныч авырулары чыганаклары барлыкка килгәндә яисә таралганда милекчегә терлекләр һәм (яисә) терлек продукциясе бәясен түләү күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан

киметелергә яисә терлекләр һәм (яисә) терлек продукциясе бәясен түләү кире кагылырга мөмкин.

5. Зыянны түләү күләме киметелергә мөмкин булган очракларның исемлеге, мондый күләмне киметү тәртибе һәм зыянны түләү кире кагылырга мөмкин булган очраклар исемлеге Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

6. Тартып алына торган терлекләрнең һәм (яисә) терлек продукциясенең бәясен билгеләүгә, терлекләр һәм (яисә) терлек продукциясе бәясен түләү күләмен киметү турындагы карарга йә терлекләр һәм (яисә) терлек продукциясе бәясен түләүне кире кагу турындагы карарга терлекләр һәм (яисә) терлек продукциясе милекчесе тарафыннан судка шикаять белдерелергә мөмкин.

7. Терлекләрнең аеруча куркыныч авырулары исемлеге һәм терлекләрнең аеруча куркыныч авырулары чыганакларын юкка чыгарганда терлекләрне һәм (яисә) терлек продукциясен тартып алу тәртибе Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.»;

10) 21 статьяның 3 өлешендә «терлекчелек продуктларын» сүзләрен «терлек продукциясен» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 09 март
№ 10-ТРЗ